| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Элмэле авылы

17 декабрь 2021 ел № 14/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Җир кодексы, «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 елдагы 112-ФЗ номерлы Закон нигезендә, прокурор протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советының 25.01.2014 ел, №34/2 карары (09.04.2019, №50/1; 01.06.2021, № 8/1 редакциясендә), белән расланган "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Яңа Чокалы авылы, Совет урамы, 20 нче йорт; Совет урамы, 35 нче йорт буенча Яңа Әлмәле авылында урнашкан Яңа Әлмәле авылы административ бинасын Яңа Әлмәле авыл җирлегенең рәсми сайтында (nilm-droganoye.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков

Кушымта
Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Әлмәле авыл җирлеге
Советы 2021 елның
17 декабре № 14/5 карары
белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр

**1) 16 статьяның 1 пунктында** «капиталь төзелеш» сүзләреннән соң «мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә әзерләнә» сүзләрен өстәргә:;

**2) 30 статьяда:**

**а) 2 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

**«6)** территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул итү.»;

**в) 6 пунктта** «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн»сүзләренә алмаштырырга.;

**3) 36 статьяның 8 пунктындагы** дүртенче абзацын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән алмаштырырга;

«Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану илнең оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яки тыелырга мөмкин.

Территорияләрне файдалану өчен махсус шартлары булган торак пунктлар һәм зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормыш һәм сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау, биналар һәм корылмаларның сакланышы, шул исәптән тау эшләнмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле башка корылмаларның сакланышы куркынычын тудыра алган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

Аеруча саклана торган табигый территорияләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.».